Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Югары Уратма торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең Югары Уратма торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Югары Уратма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны Бакча урамы буенча юлларны төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Макаровка авыл җирлеге башлыгы

«СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ»

А.Н. Кудряшов